Azatlıq Radiosı

ЧИТАЕМ НА ТАТАРСКОМ

# Озын-озак балачак (Долгое-долгое детство) — Мостай Кәрим

әле генә





**Сегодня в рубрике "Читаем на татарском" предлагаем вам ознакомиться с повестью Мустая Карима "Озын-озак балачак" – "Долгое-долгое детство". Он был написан в 1976 году.**

Это автобиографическое произведение о детстве автора в деревне Башкортостана. Взрослый рассказчик вспоминает события своего детства и людей, которые его окружали. Мы выбрали важный отрывок произведения под названием "**Акйолдыз**". Это трогательная и драматичная история любви двух сердец – Акйолдыз и Мирахима. Эта история раскрывает темы любви, верности и человеческого достоинства, а также знакомит читателя с традициями и нравственными ценностями нашего народа.

История любви Акйолдыз и Мирахима получила яркое сценическое воплощение в спектакле Рифката Исрафилова "**Яҙмыштарҙан уҙмыш бар**". Роль Мираһима

исполнил легендарный, ныне покойный **Фидан Гафаров**, а Акйолдыз – **Танчулпан Бабичева**. Несколько лет тому назад Казанский татарский ТЮЗ тоже поставил спектакль по этой повести.

Отрывок повести сокращен и адаптирован.




↗ **аудио уйнаткыч**

**йөкләү**

Иртәгә сабан туе дигәндә, күршебезгә килен төште. Терәлеп торган ут күршегә түгел, арырагына – бер өй ашасына. Хәлле генә көн иткән Галләм карт уртанчы улын – йомык Хәмзәне шулай башлы-күзле ясады. Килен ерактан килде, диделәр – Дим уреннән. Килене килен генә түгел, күрер күзгә тамаша, сизгер күңелгә бер могҗиза иде. Безнең авылда да чибәр кызларны, сылу киленнәрне, куштан хатыннарны үләт кырмаган. Шөкер, исәннәр. Кызларның сылулары үзебезнең егетләрдән дә артмый. Арту гына түгел, хәтта җитми дә кала әле. Шулай булмаса, әлеге Хәмзә, әллә кая Дим урена барып, кәләш эйттереп йөрер идемени? Чибәрләре белән дан тоткан авылга төшкән бу килен шулай да бозау көтүенә адашып килеп кергән болан баласына охшый иде. Төсе-башы, торышы-йөреше белән дә, күз карашы, хәтта тавышы белән дә безнең өчен ят, сәер, тылсымлы иде, гүя, ул бөтенләй башка туфракта, башка күк астында, башка һаваны сулап үскән. Эчкәне дә су түгел, мөгаен, ширбәт булгандыр. Югыйсә шундый ягымлы тавыш каян килсен ди ул? Исеме дә моңача колак ишетмәгән исем бит – Акйолдыз.

Акйолдызның, кыз-кыркынга ияреп, су юлынан кайтуын бөтен урам, тамаша кылып, каршы алды. Киленнең ике чиләге дә мөлдерәмә тулы иде. Ичмасам, бер тамчысы чайпалсын ла! Атлаганда, үкчәләре җиргә тими, тик аяк очлары гына кагылып кала. Үзе сизелер-сизелмәс кенә елмая. Нәрсә күреп елмая икән ул? Койма башында әсирләнеп утырган уникe яшьлек мин бичараны шәйлиме икән? Шулай да кемгә елмая ул – үз-үзенәме, кешеләргәме, әллә бөтен дөньягамы? Бер карасаң, менә-менә, тыела алмый, елап җибәрер дә кебек ул...

Килен төшкән Галләмнәр йортында шау-шулы мәҗлес төн уртасына кадәр барды. Без Сәлих агаем белән ике буйдак лапас башында кунабыз. Нәкъ шушы мәл Түбән очтан дулкын-дулкын булып гармун моңы агылып килде. Башта ул кемгәдер

йомшак кына, ягымлы гына сузып эндәшкәндәй булды, аннан соң ярсып-ярсып эч серләрен сөйләргә кереште, бара торгач, нәрсәдер инәлергә, ялварырга, үтенергә тотынды, азак килеп, үкереп елап җибәрде; кинәт тынды да буылып-буылып үксеп алды. Юк, гармун үз яшеннән үзе чәчәмәде. Ул чак кына тын алды да, ашкынып-ашкынып сайрап, төнге галәмгә үзенең булачак шатлыкларын, өметләрен, күкрәгенә сыймас дәртләрен сибә башлады. Бу моң агышын мин инде ишетәм генә түгел, хәтта күрәм дә төсле. Ул агыш, нурлар чәчә-чәчә, Түбән очтан Югары очка сузыла.

— Мәрәһимнең тагы җене кузгалды, ахрысы, — диде Сәлих агаем йокы аралаш.

Их, агаем! Нигә шулай дидең инде? Җеннең ни кысылышы бар монда? Син шулай дидең дә хырылдап йоклап киттең, ә үзең шул бер авыз сүзең белән әле генә бөтен дөньяны сихерләп алган моңны, искиткеч якты балкышны сүндердең.

Олы инәем, мөгаен, алай итмәс иде. "Кемнедер эзләп чыкты янә бу бахыр Мәрәһимнең ялгыз җаны", – дияр иде. Мин җаным-тәнем белән Мәрәһим яклымын. Аның зары да, куанычы да төнге бушлыкка батып югалмый, минем күңелемә сеңә бара. Бу сәгатьтә бөтен җиһанда без бары икәү генәбез сыман — ул да мин...

Безнең Черчә урамы башта Акйолдызның чибәрлегенә, сылулыгына сокланды, тора-бара аның уңганлыгына, булдыклылыгына хәйран калды. Галләм килене эрләгән җеп, суккан киндер ефәккә алыштыргысыз, кискән токмачы кылдан нечкә, кием тексә, коеп куя, дип сөйлиләр. Моңа кадәр дүрт аягын тышаулагач кына саудыра торган ала сыерлары, хәзер көтүдән кайткач та, килен артыннан үзе ияреп йөри. Анысы хак. Көн дә үзебез күреп торабыз. Галләмнең чыгымчы җирән биясе дә Ходай мәхлугына әйләнде. Бер тапкыр ире белән утынга барганда, Акйолдыз, дилбегәне үз кулына алып: "Әйдә, малкай, әйдә, акыллым, әйдә, күндәмем!" – дип кенә әйткән, имеш. Шушы сүзләрне ишеткән җирән бия әйләнеп караган да ике тапкыр баш каккан, янәсе, төшендем, моннан ары син әйткәнчә булырмын...

Килен төшкәннән соң ашык-пошык җәй узды, саргаеп, моңаеп көз үтте, башланмаган озын бер кыш бетте, ерганаклардан янә кар сулары йөгерде. Менә күпме заман Мәрәһимнең гармуны бер генә тапкыр да тавыш чыгармады. Бөтенләй телдән язды. Баштарак кешеләр моңа бик аптырады, хәтта хәтерләре калды, күңелләре төште. Күрәсең, бичара Мәрәһимнең җаны тәмам адашкандыр, эзләгәнен табудан өмет өзгәндер...

... Кечкенә вакытта минем ифрат алама бер гадәтем бар иде. Кичтән юрган астына кереп чумам да, йоклаган булып, олыларның сөйләшкәнен тыңлап ятам.

Җитмәсә, шартына китереп, ара-тирә мышнап та җибәрәм. Мин инде байтактан бирле юрган астында ятам. Өйдә бары ике инәем генә. Олы инәем нәрсәдер яманып утыра. Кече инәем казан төбе кыра.

— Ишеттеңме әле, ил өстендә имеш-мимеш йөри бит,— диде Кече инәем,— Мәрәһим белән Акйолдыз хакында.

— Пыш-пыш йөргән һәр хәбәрне тыңлый калсаң, зиһенеңә көч килер. Куй, Вазифа! — дип кырт кисте Олы инәем.

Бөтен ишеткәнен сөйләп бетерми туктарга Кече инәемнең чамасы юк иде.

— Бик каты гыйшык тотышканнар, ди, Таһир белән Зөһрә кебек...

Олы инәем көрсенеп куйды. Бераздан тыныч кына әйтеп салды:

— Мәхәббәт язык түгел. Мәхәббәтсез уйнаш язык. Әгәр дә син безнекенә яратып килмәсәң, белмим, ничек икебез бер дөньяга сыеп яшәр идек... Мәхәббәт бөтенесен дә аклата, ярлыката...

— Языгын да, савабын да үзе өчен һәркем үзе күтәрә. Мин бит аларны гаепләп әйтмим,— дип акланды Кече инәем.

Байтак эндәшми торгач, ул тагы тезеп алып китте.

— Мәрәһим белән Акйолдыз, күрәсең, электән үк бер-берсен белгәннәр. Теге елны безнең авылныкылар Дим үренә барып уракка ялланганнар иде бит. Шунда күрешкәннәр, диләр. Имеш, Акйолдызның риза булып Хәмзәгә килүе дә шул Мәрәһим өчен генә икән. "Мәрәһимне гомеремдә тагы бер күрер булсам, Хәмзәгә кияүгә чыгарга гына түгел, туп-туры җәһәннәмгә китәргә дә ризамын",— дип әйткән диме, уйлаган диме. — Хәерсезгә, адәмнәр артыграгын белә, аннан да артыграгын сөйли. — Мәрәһимнең яше дә утызга җитеп барадыр инде,— дигән булды Кече инәем, янәсе, сүзен очлап.

Менә нинди серләр ачылды миңа! Мәрәһим белән Акйолдызның хәлен аңлыйм мин. Тик анавы имеш-мимеш һич кенә дә дөрескә охшамый. Әниемнәр сөйләшкән теге кичтән соң атна узды, ай узды, ә гашыйклар хакында урамда ләм-мим сүз юк. Безнең Югары оч халкы, гаеп табып, кеше чәйнәргә, мыскыл итеп көләргә ифрат әвәс — сылтавы гына табылсын. "Фәләннең бичәсе фәләннең иренә күз кыскан икән, фәлән кода фәлән кодачасын аздыра язган икән, фәлән агай фәлән тол бичәнең тәрәзәсен чиерткән икән..." кебек юк-бар хәбәрне хатыннар сөт аерткан җирдә, ирләр каравыл өенә җыелганда, кыз-кыркын суга

барганда авыз тутырып сөйли. Әсгать кебек җор сүзеләр әчкелтем-төчкелтем төртмә җыр да чыгара. Әмма Акйолдыз белән Мәрәһимгә җил-яңгыр кагылмый. Димәк, Кече инәемә кемдер бөтенләй буш хәбәр сөйләгән, сөйләгән дә тынган. Ярый, хәерлесе шулдыр. Онытыйк инде бу хакта... Ләкин алар үзләре оныттырмады.

***

"Адәм ышанмас сүзне дөрес булса да сөйләмә",— диләр. Әйе, үзең күреп, үзең ишеткәнгә дә кайчак ышанып бетмисең. Расмы икән, дип икеләнәсең. Мин дә тәүдә күзем күреп, колагым ишеткәннәрнең хаклыгына шикләнеп, югалып калдым. Бу шаһитлыгыма сәбәпче безнең гел әллә кая югалып йөри торган кышлау үгезебез булды. Кич ул тагы көтүдән кайтмады. Шуны эзләп без, өйдәге ир-ат, көтү йөргән тугайның төрлебез төрле ягына таралыштык. Минем әлсерәп йөрүем бушка гына булды. Үгез табылмады. Әллә кайчан әңгер төшеп, төн тәмам куерып беткәндә, мин, арып-талып, Кызлар тавына килеп мендем. Көндез Мортаза агаемның кесәсеннән чәлдергән бер чеметем тәмәкене төреп тартмакчы булып, тау битләвендәге ялгыз имән төбенә утырдым. Кәгазен табып, тәмәкесен урадым, ә шырпысын таба алмадым. Күрәсең, каядыр төшереп калдырганмын. Ризыкка язмады бу хәрамнан килгән мал! Инде кузгалып киттем дигәндә, күземә галәмәт зур сәер нәрсә чалынды. Адәм дисәң, адәм түгел, җанвар дисәң, җанвар түгел. Үзе шөкәтсез. Ул тау астыннан акрын гына өскә, миңа табан, үрмәли. Минем җаным бармак очыма килеп җитте. Менә-менә атылып чыгып китәчәк ул. Мин сак кына имән артына сыенам, йөрәгем дөп-дөп тибүдән имән селкенә. Теге гыйфритне инде ачыграк шәйлим. Аның аяклары да, башы да икешәр, куллары әллә дүрт, әллә алты. Санап бетерерлек түгел. Агач башына үрмәләсәм инде? Алай да котылып булмас шул. Ни күрсәм дә шунда күрермен, кымшанырга ярамый. Кышлау үгезне эзлим дип, әҗәлемне эзләп йөргәнмен икән. Чытырдатып күзләремне йомдым, йомылган күз алдымнан безнең таш зират капкасы, мәчет ае, яңа гына казылган кабер чагылып үтте. Мин аларны, гүя, табутта яткан килеш күреп барам...

— Яратасыңмы? — диде гыйфритнең бер башы ирләр тавышы белән.

— Яратам... Яратам...— дип үтә ягымлы раслады хатын тавышлы баш.

— Бик, бикме? — дип төпчende тегесе.

— Бик-бик-бик булмаса, шушы бер чеметем бәхет өчен шул чаклы газап йөкләре йөкләп йөрер идеммени? Барыбер үкенмим. Синең кочагыңдагы кечкенә бәхетемне алтын тауларга алыштырачагым юк.

Шул чак чут итеп кош сайрап куйды.

— Шул коe сине энә теге ак йолдызга алып менимме? — диде ир тавышы.— Синең йолдызыңа...

Күк йөзендә, чынлап та, ак йолдыз балкып яна иде. Ул, талпына-талпына, җиргә табан омтылып куя. Менә-менә күктән ычкынып китәр дә Кызлар тавына килеп кунар төсле. Мин инде тынычлана төштем. Гыйфрит дигәнем миңа зыян китермәячәк. Аның кайгысы миндә түгел.

— Синең белән җирдә дә бик рәхәт миңа. Ул йолдызда нәрсә калган безгә. Мин үз исемемне болай да яратмыйм. Сине генә яратам — исемеңне дә, үзеңне дә... Күңелем гомер буе сине эзләде, сине зарыгып көтте...

— Эзләгән – тапкан, ташка кадак каккан, —дип такмаклады хатын.— Сабыр итеп көткән – сөйгән ярын үпкән.

— Син һич кенә дә боекмыйсың, Акйолдыз, ә мин гел сагыштамын,— дип зарланды ир. — Әйттем бит, икебез бергә чакта, бу дөньяда минем өчен сагыш та, хәсрәт тә, хәвеф тә юк. Аларның урыны башка җирдә.

Ике кулын алга сузып, пәһлеван Мәрәһим, Акйолдызны, бәби тоткан шикелле күтәреп, минем яннан гына узып китте. Тау башына менеп китте. Мине күрмәделәр. Гашыйкларның күзе җирдәге бөҗәктә түгел, һавадагы бөркеттә икәнен мин шул төнне тәү тапкыр аңладым. Сөешкән кешеләрнең ни өчен биеккә, тау түбәләренә омтылуын шул көнне мин беренче тапкыр сизендем, ә ни өчен икәнен менә сүз белән әйтеп аңлатып булмый. Матур тавышлары, сөйләгән сүзләре ошады миңа.

***

Ничек итеп кенә эчемә сыйдырыйм бу серемне? Бер көн чыдадым, ике көн чыдадым. Өченче көн чыдар әмәл калмады. Мәчет манарасына мен дә азан урынына кычкыр хет. Аулак мәлне туры китереп, Олы инәемне алачыкка чакырып чыгардым.

— Нәрсә, каймак ашыйсың килдемени, синнай? — диде ул.

— Юк, Олы инәем. Минем сиңа әйтә торган серем бар.

— Алай каймактан да баш тартырлык булгач, хәтәр сердер, күрәсең.

— Хәтәр шул, Олы инәем. Акйолдыз белән Мәрәһим хакындагы теге сүз дөрес булып чыкты бит.

— Нинди сүз, кем сүзе?

— Нигә, теге кичне Кече инәем...

Минем телем, тешемә тиеп, абынып калды. Шымчылыгым чак-чак кына ачылмады.

— Кеше сүзе инде, халык сүзе...— дип мыгырдадым.

— Куй, бушны сөйләмә.

— Буш түгел шул! Теге төнне үгез эзләп гаеп булганымда аларның икесен бергә Кызлар тавында күрдем.

— Тфү, тфү, балам, күзеңә күренгәндер. Кара төндә бәндә күзенә әллә нәрсәләр аймылышып күренә ул. Төн бик караңгы иде шул.

— Мин аларның сүзләрен дә ишеттем, Олы инәем. Валлаһи! Икмәктер, кояштыр! Мин алдакчымыни?

— Алдакчы түгел. Хата күргәнсең, ялгыш күргәнсең. Хаталану ул алдашуга керми.

— Күрдем дә, ишеттем дә.

— Адәмнең кайчак шулай күзе тиешсезне күрер, колагы тиешсезне ишетер була. Куй, балам, юк белән башыңны бутама.

Мин бөтенесен дә тезеп сөйләп бирмәкче идем дә, Олы инәем ышанырдай булмагач, сөйләмәдем.

— Адәм ышанмас сүзне сөйләмә моннан соң, — диде ул ахырда. — Гайбәтче яманаты күтәреп мәсхәрәгә калырсың. Мәсхәрә калудан без бөтен өй эчебез белән куркабыз.

Чынлап та, әллә бөтенесе дә күземә генә күрендеме икән? Олы инәем, шулай гына булгандыр, ди бит. Ә колагыма өзлексез чыңлап торган: "Яратасыңмы?", "Яратам"...

— дигән авазларны ничек басарга соң миңа? Минем колагымда тынса да, ул авазлар Кызлар тавында барыбер калачак бит.

...Олы инәемнең сәер бу адымын — минем дөрес хәбәремне көчләп-көчләп нахакка чыгарырга тырышуын мин бары әле килеп төшендем. Борынгы грекларда гашыйкларны яклаучы, аларны хәвеф-хәтәрдән саклаучы Афродита исемле илаһия булган. Минем Олы инәем, әлбәттә, ул илаһия турында ишетмәгән дә, белмәгән дә... Әмма үзе дә сизмәстән, ул Акйолдыз белән Мәрәһимнең мәхәббәтен саклаучы шул Аллаһ вазифасын үтәгән.

***

Без быел арыш урагына өмә ясарга ниятләдек. Мич башын да ике мичкә балыбыз үкереп әчеп утыра. Сугымга үгезне тәгаенләдек. Төшкелекне ашатыр өчен олы-олы өч тәпән баллы катык оетмакчы булдык. Күп итеп икмәк пешердек, калач салдык. Урак өмәсе — үзе бер бәйрәм ул. Көн буе янып-пешеп эшлиләр дә кичен ихата тутырып табынга җыелалар. Ит согыналар, шулпа чүмерәләр. Олырак ир-ат, чаярак бичәләр шау-шу килеп бал эчә. Егет-җиләнбелән кыз-кыркын табыны болай да кызмача була. Өмәгә сайлап кына, кулыннан эш килер, кичен табын кадерен белер кешеләрне генә чакыралар. Анда эләгү мәртәбәгә санала. Дүрт-биш көн алдан ук без кичке чәй вакытында кемне-кемне чакырачагыбызны чамалап, барлап чыктык. Мин хисапчы эшен башкардым.

— Мәрәһимгә әйтәсездер бит? — диде Олы инәем.

— Бичәсе чирле икән,— диде Сәлих агаем ашыга-пошыга.

— Үзе килер, — диде Олы инәем.

Мин каләм белән сыза барган кәгазьгә тагы бер таяк өстәлде.

— Күрше-күләннең һәммәсенә дә кагылдыгызмы? — дип белеште бу юлы әтием.

— Галләмнәргә генә сугылмадык йомык Хәмзә барыбер өненнән чыкмас, дидек,— дип җаваплады өлкән агаем.

— Килмәсә, чакыруыбыз калсын. Күрше хакы бар. Хәтер калыштан булмасын...

Мин тагы ике таяк өстәп куйдым. Шуның белән вәссәлам. Кояш чыгуга, безнең капка төбендә мәхшәр кайный иде. Кулбашларына ураклырын салып,

бөтенесе дә килгәннәр. Мәрәһим дә, Хәмзә белән Акйолдыз да бар. Быел арыш басуы ерак. Җәяүләп озак барырга кирәк булачак. Минем күзем, билгеле, теге икәүдә. Алар бер-берсеннән качмый да, сарылып та бармый. Акйолдыз кыз-кыркын арасында. Алар шырык-шырык көлешәләр. Култык астына кыңгыраулы гармунын кыстырган Мәрәһим, Мортаза агаем белән сөйләшкән булып, ике генә адым арырак басып тора. Әйтерсең, алар Кызлар тавына да менмәгән, чут-чут үбешмәгән дә... Болар бөтенләй икенче кешеләр. Теге төнне мин, димәк, бүтән ир белән бүтән хатынны күргәнмен булып чыга. Әмма аларга сыный биреп караучы бер мин генә түгел икән. Әле теге якта, әле бу якта шул икәүнең я монысына, я тегесенә юнәлгән күз карашы елт-елт итеп кала.

Күк алашаны җигеп, капкадан әтием чыкты.

— Я, өмәчеләр, хәерле сәгатьтә! Кузгалыйк,—диде.— Утырышыгыз арбаларга. Кызларның иң уңганнарын, иң чибәрләрен үз яныма алам. Арба минеке, җыр сезнеке...

Кинәт ыгы-зыгы купты. Кыз-кыркын белән килен-киштә, чыр-чу килеп, әле теге арбага, әле бу арбага барып сугылды. Мин, нишләптер, шунда Акйолдызга борылып карадым. Алдагы атлар кузгалып китте. Бары өч кеше генә нәрсәгәдер икеләнгән, аптырагансыман, өч яры һаман басып тора, әйтерсең, өч багана: Хәмзә, Акйолдыз, Мәрәһим. Менә Мәрәһим дә, җәһәт кенә борылып, Мортаза агаемның арбасына сикерде. Киттеләр. Акйолдыз белән Хәмзә әтиемнең арбасына утырды.

***

Төштән соң басудагы арышны ике төркем бергә кушылып урды. Өмә вакытында, халык күп булгач, җирнең буена түгел, аркылысына төшеп уралар. Ниса апа белән Хәмзә арасында торган Акйолдыз кинәт атылып алга чыкты. Чыкты да ялт итеп артына борылды. Башта ул бала итәкле яшел сатин күлмәгенең итәген ике яктан кыстырып куйды, терсәгенә чаклы җиңнәрен сызганды, чулпылары чылтырап торган ике толымын, бер кат муенына урап, артка салып бәйләде. Шуннан гына кызыл саплы ай урагын уң кулы белән тартып алды. Аның күзендә моңача безгә таныш булмаган чая очкыннар сикерешеп уйнады. Нәрсә булыр икән? Кымшанган да адәм юк. Бөтен күзләр бер Акйолдызга төбәлгән.

— Безнең якта ирләр ашта түгел, эштә ярыша! — диде Акйолдыз. Аның тавышы, элекке кебек үк, чылтырап чыңлап китте. Чәм дә, гамь дә юк кебек иде бу тавышта. — Йөрәге җиткән ир чыксын минем белән алышка! Кайсыгыз тәвәккәлрәк ? Ягез.

Өмәчеләр, әле булса ни дияргә дә белми, аптырап тора. Акйолдыз, үчекли биреп, тагы эндәште:

— Ир заты юкмыни бу авылда?

Мин, үзем дә сизмәстән, күзләрем белән Мәрәһимне эзләп таптым. Ул ызанның арырак очында башын иеп тора. "Сиңа әйтә бит, сиңа! Нәрсә җебеп торасың анда?" — дип кычкырасым килде.

— Давай, Хәмзә, — диде безнең кода, — бичәң белән ярышып, булмаса, үзең күрсәт әле ирлегеңне!

— Әйдә, Хәмзә, әйдә! — диештеләр бүтәннәр.

— Мыек дөрес әйтә. Хәмзә ярышсын! Күрик әйдә!

— Күрмирәк торсаң да ярар, — дип мөңгерәде Хәмзә. — Мин үз бичәмне ярышсыз да әллә кайчан җиңгәнмен. Ярышып маташырга ничу.

Шау-шу беразга янә тынды.

— Авылыбыз белән мәсхәрәгә калабыз бит, агай- эне! — дип үрсәләнергә кереште безнең кодабыз. — Үзем чыгар идем, урагым үтмәс, кулым — булдыксыз. Тел белән урып булмый шул. Миннән башка бер генә чая ир дә юкмыни?

Ызан буйлап салмак кына атлап, Акйолдыз каршысына Мәрәһим килеп басты. Аның мәһабәт гәүдәсе янында буйга-сынга кайтышрак кеше гадәттә тагы да кечерәеп, мескенләнеп кала. Шуңа күрә кәрлә адәмнәр аның тирәсендә чуалмаска тырыша. Ә бу юлы нечкә генә Акйолдыз пәһлеван алдында бәләкәйләнеп, югалып калмады, ничектер үсеп, гайрәтләнеп киткәндәй булды. Менә бер могҗиза!

— Мин чыгам, — диде баһадир. — Өчәр адым үлчә, Мортаза.— Үзе бары шунда гына Акйолдызның йөзенә күтәрелеп карады. Тегесенең ике битендә әлеге кызыллык гөлт итеп балкыды да тиз үк сүнде.

— "Батыр үлеме бичәдән" дигәнне ишеткәнебез бар.—Мәрәһим кинәт батыраеп китте. — Ни булса да булыр, Акйолдыздан җиңелеп хурлыкка калуымны да бер мәртәбәгә, бер бүләккә санармын.

— Бигүк кыйммәтле бүләк өмет итмисең икән, Мәрәһим… — Акйолдызның матур иреннәрендә беленер-беленмәс кенә елмаю чагылып калды.

— Язганы шул булса ни… — дип тегесе дә көлемсерәгәндәй итте.

Үзенең зәңгәр күзләре шундый боек иде. Ул иңбашындагы урагын алды. Күзләре кинәт җанланып китте.

—Тәвәккәлләдек, Акйолдыз! Син янсаң, мин сүнмәм …

Нинди матур сүзләр әйтеп салды Мәрәһим! Мин ул сүзләрнең асылына яхшы төшенәм. Бүтәннәрнең, әлбәттә, моңа зиһене җитми.

Бу арада Мортаза агаем ызаннан өчәр адым үлчәде, тип-тигез ике бүлем булды – гаделнең дә гаделе килеп чыкты. Хәзер башланачак. Мин Акйолдыз өчен хафаланмыйм . Аның беренче уракчы икәне илгә мәгълүм. Мәрәһим өчен борчылам менә. Дөрес, ул да эшкә уңган ир, булдыклы, маһир кеше. Ул читән үрсә, кызлар бәйләгән челтәр шикелле купшы килеп чыга. Кибән салса, чиркәү гөмбәзе шикелле килбәтле була. Ул ясап буяган тәрәзә капкачлары әллә каян елмаеп тора. Хәтта урманнан утын алып кайтканда да йөген ничек итте алай өйми, аны ыспай итеп, картинка кебек итеп төйи. Гармунны ничегрәк уйнавын әйтеп тә тормыйм инде, уенын бөтен тирә-як үзе ишетеп тора, ә менә уракка ничегрәк икән — кулыннан килә микән?

— Я, башлагыз! Җиңелгән еламасын. — Әлегә кадәр бәхәскә катнашмый торган әтием ярышчыларга шулай дип фатихасын бирде.

Акйолдыз белән Мәрәһим уртадагы бауның икесе ике ягына килеп басты. Бу икәү бер-берсен шушы сары дәрьяга батырырмы, әллә, киресенчә, коткарып алып чыгармы? Икесе дә жәл миңа, чөнки алар минем кешеләрем. Мин аларның серен саклыйм. Хәзер инде бу серне бүтән кешегә чишәсем дә килми. Ул минеке генә, юк, Олы инәем белән икебезнеке генә…

Акйолдызның кызыл саплы елтыр урагы беренче кабымын кырт иттереп тешләп өзде. Икенчесен, өченчесен дә чеметте. Шуннан китте бу, әй китте! Уң кулындагы урагы елт-елт итеп кенә кала, сул кулындагы учмасы урак көенә, ничектер, әйләнә-әйләнә биеп бара. Учмасы тулгач, урагы белән башак янышнан тота биреп, аны артка әйләндереп сала. Елтыр урак бөтенләй ярсыды, бөтенләй шашты. Азактан тыеп туктатып булса ярар иде… Урак уру түгел бу, торганы белән бер тамаша — бәйге! Күзне аерып алып булмый, ә шулай да аерырга кирәк. Чөнки янәшәдә икенчесе бар. Мәрәһимнең көрәк чаклы учына берьюлы ярты көлтә сыядыр.

Монысы салмак салдыра, ләкин бер селтәүдә әллә ничаклы ялмап ала. Ай-һай, Алпамшамыни?!

Ярышны моңача тавыш-тынсыз гына күзәткән кешләр, һәркем үзенчә, я куана, я борчыла башлады. Берәүләр Акйолдызны дәртләндерде: "һай, килене дә килене! Килен түгел, хәзинә!" Икенчеләр Мәрәһимне әйдәде; "Әй, гармунчы, ешрак бас урагың телләренә!". Кемдер мәзәк чыгарды. Кемнәрдер шуңа хахылдап көлеп җибәрде. Ниса апам чыдамады, ике кулын бөеренә таянып, теге ерык авызлар алдына килеп басты.

— Тыйнаксызлар, хәсисләр! Монавы хозур тамашаны, мөнәҗәт тыңлаган төсле, тын да алмый карау тиешле. Күңел биребрәк карагыз, юньсезләр. — Аның тавышы кинәт йомшарып, йөзе яктырып китте.— Сөбханалла- машалла! Тфү, тфү, күз тимәсен. Матурлык белән Көч ярыша бит монда! Чибәрлек белән Гайрәт алыша. Шундый бәйрәмне гомердә бер генә тапкыр күрергә мөмкин. Соклана белергә кирәк...

Ниса апамның сүзләреннән соң бу ярыш бөтенләй бүтән сыйфатка кереп, бүтән мәгънә алгансыман булды. "Матурлык белән Көч ярыша бит монда!.." Кайсысы җиңәр икән боларның? Нәкъ мөнәҗәт тыңлагандагы шикелле, халык тынып калды.

Акйолдыз инде көлтә бәйләргә тотынды. Ни арада бавын ясый, ни арада учмаларын җыя, ни арада көлтәсен буып ташлый. Артында тәгәрәшеп кенә торалар. Көлтәләре дә көлтә генә түгел, тыгыз билле сары курчак сынлы: шундый ыспайлар, көлеп торалар. Шулай да бу эштә Мәрәһим тагы да җитезрәк булып чыкты. Байтак соңлап тотынса да, ярты юлны үтүгә, ул Акйолдызны куып җитте. Менә Акйолдыз соңгы көлтәсен бәйләде дә, селти биреп, аны Мәрәһим ягына ыргытты. Ә Мәраһим бәйләгән галәмәт юан көлтәсен хатын алдына китереп бастырды. Үзе, башын ия биреп, тынып калды. Акйолдызның иреннәре буйлап әлеге арбаучан елмаю йөгерде. Ул тәүдә толымнарын чишеп артка ташлады, кыстырылган итәкләрен тартып төшерде. Шуннан гына Мәрәһимнең зәңгәр күзләренә туп-туры карап:

— Ир икәнсең, Мәрәһим... — диде.

"Мөнәҗәт тыңлау" тынлыгы шартлап ярылды. Кешеләр, үзләре җиңеп чыккан шикелле, бөтенесе берьюлы иркен тын алды. Рәхәт итеп тын алды.

Ике уракчы арасына этием килеп басты. Ниндидер бик кирәкле сүз әйтергә уйлый, ахры. Төбеннән үк сакалын учлап тотты. Иң акыллы сүзен шулай сакалыннан сыгып чыгара ул. — Сез икегез дә җиңдегез, — диде ул. — Матур итеп

җиңдегез. Мондый җиңүчеләргә затлы бүләкләр тиеш тә бит, затлы малларым юк. Сез яшьсез, уңгансыз, матурсыз, һәркайсыгыз — үз-үзенә бүләк... Минем өмәмне олыладыгыз, күтәрдегез, ямьләдегез. Сагынып сөйләрлек тамаша ясадыгыз. Рәхмәт сиңа, килен! Мәрәһим, сиңа рәхмәт!..

Ничек кызык сөйләп ташлады әтием. Нәрсә бу — рәхмәтме, хуплаумы, сокланумы? Ә миңа калса, әтиемнең сүзләре фатиха сымаграк булып ишетелде.

***

Кич өмәчеләр табынга җыелды. Ихатаның төрле җиренә паласлар җәеп әзерләгән кичке табында Мәрәһим белән Акйолдыз кара-каршы туры килде. Мин лапас башыннан бөтенесен дә күреп утырам. Мәрәһим ашамады да, эчмәде дә, баштан ахырга кадәр бары гармун гына уйнады. Әй уйнады да соң! Бер арада Мәрәһим безнең якта бөтенләй ишетелмәгән матур озын көй тартып җибәрде, уйнап чыкты да тагын башлады. Бөтен табынны хәйран калдырып, Акйолдызның йомшак моңлы тавышы яңгырады. Хәйран калуыбыз шуннан: елдан артык вакыт үтеп, аның җырлавын тәү тапкыр ишетәбез. Нинди матур, талгын җырлый Акйолдыз. Табында шау-шу тиз үк басылды. Моңа кадәр, күршесен дә тыңламый, тик үз сүзен генә сөйләп утырган кызмача ирләр дә тынып калды. Шушы җыр — Акйолдызның безгә мәгълүм гомерендәге тәүге һәм соңгы җыры булды. Аның моңлы тавышын башкача мин дә, бүтәннәр дә ишетмәдек. Куанычларын да, хәсрәтләрен дә җырсыз уздырды ул.

... Иртәгесен таң белән Мәрәһим башын алып чыгып китте. Куенына бер түгәрәк икмәк тыккан, култык астына гармунын кыстырган да шулай авылдан чыгып киткән. "Мине тиз арада көтмә, мин озак кәсепкә юл тоттым", — дигән ул хатынына.

Мәрәһим урам капкасыннан түгел, ындыр артыннан чыгып киткән. Шуннан, Галләм картның бакча артына килеп, бик озак басып торган. Торган, торган да, кинәт борылып, тугай ягына йөгергән. Имеш, башкача авылга әйләнеп тә карамаган. Боларны кем күзәтеп торгандыр, анысы безгә караңгы. Атна үтте, ай үтте. Ә Мәрәһимнән хат та, хәбәр дә юк. Халык шомлана башлады. Шулай да каз өмәләре чорында кош теледәй генә хат килеп төшкән бугай. Анда да исән-саулыгын гына сөйләгән дә йөкле калган бичәсенә үтенечен әйткән: "Ул туса, исемен үзең тап, кыз туса, Акйолдыз дип куш", — дигән. Хатын иренең сүзеннән чыкмаган. Ыжгырып торган январь числосында дөнья күргән кыз балага атасы теләгән исемне бирде — Акйолдыз дип кушты.

***

Еллар узачак, сугыш барысының да гомерен чәлпәрәмә китерәчәк . Мәрәһимне һәм берничә ир-егетне сугышның беренче көннәрендә үк сугышка алып киттеләр. Аларны бөтен авыл озатты. Ирләр арбаларга утырды. Мәрәһим дә алар арасында. Аны хатыны, кызы Акйолдыз озатып калды. Читтәрәк аның гомерлек мәхәббәте Акйолдыз җиңгәбез дә минем янымда тора. Акйолдызның бармаклары минем беләгемә тирәнрәк бата. Ул урыннан кузгала да алмады, сүз дә дәшмәде.

Ирләрнең арбалары инде күренми башлагач, Мәрәһим, атын туктатып, каерылып безнең якка карады. Шулчак Акйолдыз, кыр кәҗәсе сыман кинәт үрә сикереп , китүчеләр артыннан торып йөгерде. Мәрәһим, атының башын каерып кире борды да хатынга каршы җилдереп килде . Акйолдыз чак кына егылмый калды, тегесе ирек бирмәде, гайрәтле куллары белән эләктереп алды да үз алдына утыртты. Утыртты да, арбаларны, сыбайлыларны узып, чабып китте. Аннан соң беразга күздән югалдылар. Аларны хуплаучы да, хурлаучы да булмады. Хәтта Мәрәһимнең хатыны да чыдады, буйга үзеннән чак кына кайтыш кызын җитәкләп, башкалар рәтендә кымшанмый гына карап торды. Шушы мәл мин бу хатын алдын да үземне ничектер гаепле сыман сиздем. Монысы да бит "минем кешем", ә үзем аны хәсрәтле иткән серләрне саклыйм... Бу чакта бөтенесен дә кызганам...

Сугыш бетүгә ел тулгач, Мәраһим турында "Пал смертью храбрых" дигән кара кәгазь килде. Мәрәһимнең бичәсе кар астында калган агулы бодай ашап үлгән иде. Ятим калган кызлары Акйолдызны Акйолдыз җиңгәбез тәрбиягә алды. Аның ире Хәмзә дә сугышта һәлак булды.

Чибәрлеген гомер ташламас бу җиңгәмне, байтак еллар узгач, тагын очраттым. Урамда тап булыштык. Йөзе аның яңадан яктырып киткән, ничектер тынычланып калган. Кыяфәтенә, төсенә әле булса картлык кагылмаган. Нинди ныклы токым , бирешмәс зат бу?! Ул дүрт-биш яшьлек малай җитәкләп алган. Баласы аз гына алга уздыра биреп, куанычын яшерми, әйтеп салды:

— Акйолдызның улы. Мәрәһим исемле.

Малай карт атасына шулкадәр охшаган – суйган да каплаган . Күпме ташкыннар , әйләнмәләр , өермәләр үтеп, Акйолдыз үзенең ярына килеп чыкты. Әлбәттә, күңеле көткән теләге, яшьтән җаны омтылган яры, кызганыч, шушы булмагандыр...

***

У нас есть и другой интересный текст Мустая Карима:

- Безнең өйнең яме (Мостай Кәрим)

Если у вас есть предложения по текстам, то Вы всегда можете оставить их по адресу: **eydetat@gmail.com**

Заходите на **наш сайт**, каждый день вы найдете что-то новое и интересное! Также подписывайтесь на наши соцсети: мы есть в **Telegram-e**, **Instagram-e**, **Youtube** и **Тиктоке**.

Скоро – больше! До встречи, сау булыгыз!



**БУ ТЕМАГА:**

Безнең өйнең яме (Мостай Кәрим)

This item is part of

Әйдә! Online

читаем на татарском

Азатлык Радиосы © 2026 RFE/RL, Inc. | Бар хокуклар сакланган